БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19 сентябрь 2019 ел № 207

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставын «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131 нче номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, 29 нчы август 2019 нчы елгы ачык тыңлаулар тәкъдимнәрен һәм Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 20 нче август 2019 нчы елгы 02-681ЭП номерлы тәкъдимнәрен игътибарга алып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар **кабул итте:**

**1.** Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район Советының 2016 елның 28 нче апрелендәге 37 нче номерлы карары (11 нче август 2017 нче елгы, 26 нчы июль 2018 нче елгы үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

**1.1. Уставның 6 нчы статьясындагы 1 нче пунктының 8 нче пунктчасында** «хокуклар» сүзеннән соң «төп аз санлы халыклар һәм башкалар» сүзләрен өстәргә;

**1.2. Уставның 6 нчы статьясындагы 1 нче пунктының 17 нче пунктчасын** киләсе редакциядә бәян итәргә:

«17) муниципаль районның территориаль планлаштыру схемаларын раслау, муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасы нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документларын раслау, муниципаль район территориясендә гамәлгә ашырыла торган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасын алып бару, муниципаль район чикләрендә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен резервлау һәм тартып алу, хәбәрнамәдә күрсәтелгән планлаштырылган индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм җир кишәрлегендә шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыруның рөхсәт ителгән булуы турында хәбәрнамә җибәрү, хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яки) шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру рөхсәт ителмәве турында хәбәрнамә, тиешле авылара территориядәге җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак яки бакча йортлары төзелеше яки реконструкциясе булган очракта, индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортының төзелгән яки үзгәртеп

корылган объектының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе яки туры килмәве турында хәбәрнамә, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә авылара территориядә урнашкан рөхсәтсез корылмаларны сүтү турында, авылара территориядә урнашкан рөхсәтсез корылмаларны сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар, авылара территориядә урнашкан җир кишәрлеген билгеләнгән максат буенча кулланмау яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланган очракта тартып алу турында карар кабул итү, авылара территориядә урнашкан рөхсәтсез корылмаларны сүтүне тормышка ашыру яки аны Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы таләпләренә туры китерү;»;

**1.3. Уставның 8 статьясындагы 12 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) җирлекнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау; җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документларын раслау; җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү; төзелешкә (Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш) рөхсәт бирү; җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектлары төзегәндә, үзгәртеп корганда, файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү; җирлекләрнең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау; җирлек чикләрендә муниципаль ихтыяҗлар өчен җирләрне резервлау һәм җир кишәрлекләрен алу; җирлек чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру; Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда биналарны, корылмаларны тикшерү һәм мондый тикшерү барышында ачыкланган бозуларны бетерү турында тәкъдимнәр бирү; индивидуаль торак яисә бакча йорты төзелеше яки үзгәртеп корылуы турындагы хәбәрнамәдә (алга таба-планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә) күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын урнаштыруга рөхсәт булуы турында хәбәрнамә җибәрү; планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яисә) җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын урнаштыруга рөхсәт булмавы турында хәбәрнамә җибәрү; җирлекләр территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын яки бакча йортларын төзегәндә яки үзгәртеп корганда шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килү яки туры килмәү турында хәбәрнамә җибәрү; Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү турында карар кабул итү; үзирекле корылманы сүтү яки аны территорияне планлаштыру буенча документлар яисә капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата Федераль законнар белән расланган мәҗбүри таләпләр, җир биләмәләреннән файдалану кагыйдәләре һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә рөхсәт ителгән төзелешнең һәм үзгәртеп коруның иң чик параметрларына туры китерү турында карар кабул итү; максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмый яисә Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген тартып алу турында карар кабул итү; үзирекле корылманы сүтү яки аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү.»;

**1.4.Уставның 17 нче статьясындагы 2 нче пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.Ачык тыңлаулар халык, район Советы, район башлыгы, үзенең вәкаләтләрен контракт нигезендә гамәлгә ашыручы башкарма комитет җитәкчесе инициативасы буенча үткәрелә.

Халык яки район Советы инициативасы буенча үткәрелә торган ачык тыңлаулар район Советы тарафыннан, ә район башлыгы, контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы башкарма комитет җитәкчесе инициатавасы буенча үткәрелә торган ачык тыңлаулар - район Башлыгы тарафыннан билгеләнә.»;

**1.5.Уставның 17 нче статьясындагы 2 нче пунктында** «әлеге статьяда күрсәтелгән проектлар һәм мәсьәләләр буенча,» сүзләрен төшереп калдырырга.

**1.6.Уставның 26 нчы статьясындагы 6 нчы пунктының 1 нче пунктчасын** киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнү, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу (Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партиядә, билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюзда катнашудан, съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында катнашудан тыш), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашудан тыш; муниципаль берәмлек идарә органнарында һәм оештыручысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) оештыру яки идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә тәкъдим итү; федераль законнарда каралган башка очраклар;»;

**1.7. Уставның 43 нче статьясындагы 1 нче пунктының 5 нче пунктчасының 12 нче абзацы** үз көчен югалткан дип танырга;

**1.8. Уставның 47 нче статьяның 6 нчы пунктында** «Район Башлыгы белән килешү буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

**1.9.Уставның 52 нче статьясындагы 3 нче пунктында** «Район Башлыгы белән килешү буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

**1.10. Уставның 53 нче статьяның 2 нче пунктында** «Район Башлыгы белән килешү буенча» сүзләрен төшереп калдырырга.

**1.11.**Уставны түбәндәге эчтәлекле IX бүлек белән тулыландырырга:

## IX бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ УЗУ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАЛАРНЫ БИЛӘҮ

### 55 нче статья. Гомуми нигезләмәләр

1. Муниципаль хезмәт - Муниципаль хезмәт вазыйфаларында даими нигездә хезмәт килешүе (контракт) төзү юлы белән билгеләнгән хезмәткәрләрнең һөнәри эшчәнлеге.

2. Муниципаль хезмәт вазыйфалары Татарстан Республикасы законы белән расланган Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

3. Муниципаль хезмәтне финанслау район бюджеты хисабына башкарыла.

4. Аның җенесенә, расасына, милләтенә, чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи хәленә, яшәү урынына, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, җәмәгать берләшмәләренә каравына, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең профессиональ һәм эшлекле сыйфатларына бәйле булмаган башка шартлардан бәйсез рәвештә, Россия Федерациясе дәүләт телен белүче гражданнар муниципаль хезмәткә тигез керә ала.

5. Һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яисә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кирәк булган әзерлек юнәлеше буенча эш стажына квалификация таләпләре муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен типлаштырылган квалификация таләпләре нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә, алар муниципаль хезмәт вазыйфалары классификациясе нигезендә Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

6. Вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәк булган белемнәргә һәм күнекмәләргә квалификация таләпләре муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге төренә карап вазыйфаи инструкциясе белән билгеләнә. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи Инструкциясе белән шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә квалификация таләпләре каралырга мөмкин.

**56 нчы статья. Муниципаль хезмәт вазыйфасы**

1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы - җирле үзидарә органы яисә муниципаль вазыйфаны биләүче затның вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча билгеләнгән вазыйфалар даирәсе булган, әлеге Устав нигезендә барлыкка килгән җирле үзидарә органындагы вазыйфа.

**57 нче статья. Муниципаль хезмәткәр, Муниципаль вазыйфаны биләүче зат**

1. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар булып даими нигездә гамәлдәге җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, шул исәптән районның Контроль-хисап палатасы рәисе дә тора.

2. Муниципаль хезмәткәр - федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә, район җирле бюджеты акчалары исәбеннән түләнә торган акчалата хезмәт вазыйфасы буенча вазыйфаларны башкаручы граждан.

3. Җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник тәэмин итү буенча вазыйфаларны башкаручы затлар муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләми һәм муниципаль хезмәткәрләр булып тормый.

**58 нче статья. Муниципаль хезмәткәрнең хокуклары һәм бурычлары**

1. Муниципаль хезмәткәр хокуклы:

1) муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасы буенча аның хокукларын һәм бурычларын билгели торган документлар, вазыйфаи бурычларны үтәү сыйфатын бәяләү критерийлары һәм хезмәт буенча алга таба үсү шартлары белән танышырга;

2) вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле оештыру-техник шартлар белән тәэмин ителергә;

3) хезмәт өчен түләү һәм хезмәт законнары, Муниципаль хезмәт турындагы законнар һәм хезмәт килешүе (контракт) нигезендә башка түләүләргә;

4) эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләргә, ял көннәре һәм эшләми торган бәйрәм көннәре, шулай ук ел саен түләнә торган отпуск бирү белән тәэмин ителергә;

5) билгеләнгән тәртиптә вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле мәгълүмат һәм материаллар алырга, шулай ук җирле үзидарә органы, районның сайлау комиссиясе эшчәнлеген камилләштерү турында тәкъдимнәр кертүгә;

6) үз инициативасы буенча муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашу;

7) Районның муниципаль хокукый акты нигезендә Район бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә һөнәри белем алу;

8) үз шәхси мәгълүматларын якларга;

9) шәхси эшенә керткәнче үз эшенең барлык материаллары, һөнәри эшчәнлек турында бәяләмәләр һәм башка документлар белән танышырга, шулай ук шәхси эшкә язма аңлатмаларын беркетергә;

10) һөнәр берлекләре төзү хокукын да кертеп, үз хокукларын, социаль-икътисадый һәм һөнәри мәнфәгатьләрен яклау өчен берләшергә;

11) хезмәт законнары нигезендә шәхси хезмәт бәхәсләрен карарга, муниципаль хезмәттә үз хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, шул исәптән судка шикаять бирүне дә кертеп, якларга;

12) Россия Федерациясе законнары нигезендә пенсия белән тәэмин ителергә.

2. Муниципаль хезмәткәр, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәрдән тыш, әгәр дә бу мәнфәгатьләр каршылыгына китермәсә һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 нче елның 2 нче мартында кабул ителгән 25-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса, яллаучы (эш бирүче) вәкилгә алдан язмача хәбәрнамә биреп башка түләүле эшне башкарырга хокуклы.

3. Муниципаль хезмәткәр бурычлы:

1) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль конституцион законнарны, федераль законнарны, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын, әлеге Уставны һәм районның башка муниципаль хокукый актларын үтәргә һәм аларның үтәлешен тәэмин итәргә;

2) вазыйфа йөкләмәләрен вазыйфаи инструкция нигезендә үтәргә;

3) вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда, расасына, милләтенә, теленә, дингә мөнәсәбәтенә һәм башка шартларга бәйсез рәвештә, кеше һәм гражданның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен, шулай ук оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

4) җирле үзидарә органында, район сайлау комиссиясе аппаратында билгеләнгән эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен, вазыйфаи инструкциясен, хезмәт мәгълүматы белән эшләү тәртибен үтәргә;

5) вазыйфаи бурычларны тиешенчә башкару өчен кирәкле квалификация дәрәҗәсен сакларга;

6) дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрне, шулай ук вазыйфа йөкләмәләрен үтәүгә бәйле рәвештә белгән белешмәләрне, шул исәптән гражданнарның шәхси тормышына һәм сәламәтлегенә кагылышлы яисә аларның намусына һәм абруена кагылучы белешмәләрне читкә таратмаска;

7) дәүләт һәм муниципаль милекне, шул исәптән аңа вазыйфаи бурычларны үтәү өчен бирелгән мөлкәтне сакларга;

8) Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә үзе һәм үз гаиләсе әгъзалары турында белешмәләр бирергә;

9) яллаучы (эш бирүче) вәкиленә Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыккан көнне Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгу турында яисә чит дәүләт гражданлыгын алган көнне чит ил гражданлыгы алу турында хәбәр итәргә;

10) чикләүләрне, йөкләмәләрне үтәргә, федераль законнар белән билгеләнгән тыюларны бозмаска;

11) эшкә алучы (эш бирүче) вәкилгә вазифаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык турында язма рәвештә хәбәр итәргә һәм мондый конфликтны булдырмау буенча чаралар күрергә.

4. Муниципаль хезмәткәр аңа тапшырган законсыз йөкләмәне үтәргә хокуклы түгел. Тиешле җитәкчедән муниципаль хезмәткәр фикеренчә хокуксыз булган йөкләмә алынганда, муниципаль хезмәткәр бу йөкләмәне биргән җитәкчегә, әлеге йөкләмәне үтәгәндә бозылырга мөмкин булган федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезләмәләрен күрсәтеп, язма рәвештә әлеге йөкләмәнең хокуксыз булуын нигезләргә тиеш. Әлеге язма рәвештәге йөкләмә җитәкче тарафыннан расланган очракта, муниципаль хезмәткәр аны үтәүдән баш тартырга тиеш. Хокуксыз йөкләмә үтәлгән очракта муниципаль хезмәткәр һәм бу йөкләмәне биргән җитәкче Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тотачак.

**59 нчы статья. Муниципаль хезмәткәргә бирелә торган гарантияләр**

1. Муниципаль хезмәткәргә гарантияләнә:

1) вазыйфаи инструкция нигезендә аларның вазыйфаи бурычларын үтәүне тәэмин итә торган эш шартлары;

2) акчалата тотуны үз вакытында һәм тулы күләмдә алу хокукы;

3) эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләү, ял көннәре һәм эшләми торган бәйрәм көннәре, шулай ук ел саен түләнә торган отпуск бирү белән тәэмин ителә торган ял;

4) муниципаль хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына медицина хезмәте күрсәтү, шул исәптән муниципаль хезмәткәр пенсиягә чыкканнан соң да;

5) тиешле еллар эшләгән өчен һәм инвалидлыкка бәйле рәвештә пенсия белән тәэмин итү, шулай ук аның вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә вафат булган очракта муниципаль хезмәткәрнең гаилә әгъзаларын пенсия белән тәэмин итү;

6) вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә зыян китергән очракта мәҗбүри дәүләт иминияте;

7) муниципаль хезмәт узган чорда яисә аның эше туктатылганнан соң, әмма вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә килеп чыккан авыртуы яисә эшкә яраклылыгын югалтуы очракларында мәҗбүри дәүләт социаль иминияте;

8) федераль законнарда билгеләнгән шартларда, тәртиптә һәм очракларда муниципаль хезмәткәрне һәм аның гаилә әгъзаларын вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә килеп туган янаулардан һәм башка хокуксыз гамәлләрдән саклау.

2. Җирле үзидарә органы, районның сайлау комиссиясе ябылуга яки җирле үзидарә органы, район сайлау комиссиясе аппараты хезмәткәрләре штаты кыскартылуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәр белән хезмәт килешүе өзелгәндә, муниципаль хезмәткәргә оешма ябылуга яки оешма хезмәткәрләре штаты кыскартылуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән очракларда хезмәт законнары белән билгеләнгән гарантияләр бирелә.

3. Татарстан Республикасы законнары белән муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә гарантияләр бирелергә мөмкин.

**60 нчы статья. Муниципаль хезмәткәрнең тәртип (дисциплинар) җаваплылыгы**

1. Дисциплинар җинаять кылган өчен - муниципаль хезмәткәрнең үзенә йөкләнгән хезмәт вазыйфаларын үтәмәве яки тиешенчә үтәмәве өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиле түбәндәге дисциплинар җәза кулланырга хокуклы:

1) кисәтү;

2) шелтә;

3) тиешле нигезләмәләр буенча муниципаль хезмәттән азат итү.

2. Дисциплинар җинаятькә юл куйган муниципаль хезмәткәр вакытлыча (әмма бер айдан да артык түгел), аның дисциплинар җаваплылыгы турындагы мәсьәләне хәл иткәнче, вазыйфаи бурычларын үтәүдән, акчалата тотуны саклау белән эштән азатителергә мөмкин. Муниципаль хезмәткәрне вазыйфаи бурычларны үтәүдән читләштерү бу очракта муниципаль хокукый акт белән башкарыла.

3. Дисциплинар җәзаларны куллану һәм алу тәртибе хезмәт законнары белән билгеләнә.

**1.12.** Уставның 72 статьясындагы 8 пунктны түбәндәге эчтәлекле 8.1 пункты белән тулыландырырга:

«8.1.Муниципаль берәмлек уставы, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» Россия Юстиция министрлыгы порталында дәүләт теркәвеннән соң рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш. (http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф теркәлү челтәр басмасы сыйфатында: Эл № ФС77-72471 от 05.03.2018).».

**1.13.** IX, X, XI, XII, XII, XIV, XV бүлекләрен X, XI, XI, XII, XIV, XV, XVI Устав бүлекләре дип кабул итәргә.

**1.14.** Уставның 54-87 статьяларын 60-93 статьялар дип санарга.

**2.** Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

**3.** Әлеге карар, гамәлдәге законнар белән үз көченә керүнең башка сроклары каралган нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**4.** Дәүләт теркәвенә алынганнан соң әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә.

**5.** Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары Н.Н. Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин